**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 3 апреленнән № 8-49

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Тулай торак кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтү) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 29 пунктындагы «д» пунктчасының үз көчен югалтуын тану хакында» 2026 елның 20 февралендәге 23-ФЗ номерлы Федераль законнаога, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-161 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-379 номерлы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-410 номерлы, 2025 елның 5 июнендәге 57-437 номерлы, 2025 елның 29 декабрендәге 5-33 номерлы, 2026 елның 12 мартындагы 7-42 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) торак-коммуналь хуҗалык системасында ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре булган затлар тарафыннан мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне ремонтлау эшләрен карап тоту һәм үтәү буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре

төзелгән, күпфатирлы йортта урыннарның мондый милекчеләре тарафыннан мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар, шулай ук күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләре һәм алардан файдаланучылар белән мәгълүмати хезмәттәшлеккә таләпләр;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский